СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш, Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы, Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **№6**

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

1.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 12 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 12 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 12 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 12 ноябренә 16 сәгать 00 минутта халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Тукай урамында яшәүчеләр.

2нче этап: Такташ, Урак һәм Чүкеч, Тынычлык урамында яшәүчеләр.

3нче этап: Габделхәй Кәримов, Яшьләр, Төньяк, Яр буе урамында яшәүчеләр.

4нче этап: Сәгъдуллин, Җиңү, Бакча урамында яшәүчеләр.

6. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау ( материал сатып алу һәм Шушма елгасы аша Серп и Молот урамы янында күпер салу);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, Шушмабаш авылы Тынычлык, Яшьлэр урамнарында, Бакча белән Такташ урамнары арасында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү ( һәйкәлне ремонтлау, мәңгелек ут урнаштыру);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов,Тукай урамнарында сууткәргеч челтәрен алыштыру; су насосы сатып алу; Сәгъдуллин ур., 46А адресында урнашкан су башнясын киртәләү һәм территорияне төзекләндерү)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

7. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы 1б йорт, Габделхәй Кәримов урамы 5 йорт, Габделхәй Кәримов урамы 8 йорт адреслары буенча, Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый

мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ